КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 сентябрь г.Казань № 940

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 июнь, 505 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибендә (алга таба – Тәртип):

исемендә «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1 пунктта «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«индустриаль (сәнәгать) парк(ы) – сәнәгать инфраструктурасы объектлары җыелмасы, ул тулысынча яисә өлешчә Татарстан Республикасы һәм (яки) муниципаль берәмлек милкендәге һәм (яки) хосусый милектәге күчемсез мөлкәт объектларын, шул исәптән парк эшчәнлеген тәэмин итә торган, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары эше өчен шартлар тудыруга һәм сәнәгать җитештерүен гамәлгә ашыруга билгеләнгән һәм идарәче компания тарафыннан идарә ителә торган җир кишәрлекләрен, административ, җитештерү, склад һәм башка бүлмәләр, инженерлык, һәм (яки) энергетика, һәм (яки) транспорт инфраструктурасы объектларын үз эченә ала;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сервис – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча урнашкан, субсидия алу максатларында электрон рәвештә заявка һәм документлар бирү өчен заявка бирүченең хокукларын тормышка ашыруга билгеләнгән «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасы.»;

1.4 пунктта «2021 елга» сүзләрен «тиешле финанс елына һәм план чорына» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Кире кайтару өчен субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләренә сайлап алу үткәрелә торган елга кадәрге елда кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарга түләү буенча фактта тотылган һәм документаль расланган чыгымнарның бер өлеше керә.»;

2.2 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.1 пунктта:

икенче абзацта «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ресурслар белән тәэмин итүче оешма белән төзелгән энергия белән тәэмин итү шартнамәсенең (кушымталарсыз) ресурслар белән тәэмин итүче оешма тарафыннан таныкланган күчермәсе;»;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«һәр түләү йөкләмәсе ядтылыгында кайсы чор өчен акча түләнү турында мәгълүмат бирелгән, заявкага теркәлгән түләү йөкләмәләренең номеры һәм датасы күрсәтелгән, вәкаләтле затның имзасы һәм заявка бирүченең мөһере (булганда) белән расланган аңлатма язуы.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән сервисның тиешле бүлекләре эшли башлаганга кадәр заявка кәгазьдә бер нөсхәдә тапшырыла. Сервисның тиешле бүлекләре эшләгән очракта, заявка кәгазьдә бер нөсхәдә яки сервис аша электрон формада бирелә.

Электрон рәвештә тапшырыла торган документлар сканерлау чаралары ярдәмендә тулы төс тапшыру режимында эшләнергә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Заявка биргәндә тапшырыла торган барлык документлар, шул исәптән электрон рәвештә тапшырыла торган документлар да төгәл басылып, барлык пунктлар буенча

тутырылырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела). Мөһер (булганда) сугылган һәм заявка бирүченең яки аның вәкаләтле затының имзасы белән расланган төзәтмәләрдән тыш, чистартулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми.

Заявканың барлык битләре дә номерланган булырга тиеш. Заявка тегелгән һәм, кәгазьләрнең гомуми саны күрсәтелеп, заявка бирүченең яки вәкаләтле затның имзасы һәм заявканың икенче ягында заявка бирүченең мөһере (булганда) белән расланырга тиеш.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Заявкаларны кабул итү вәкаләтле оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, заявкалар кабул ителә башлау көненә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

вәкаләтле оешманың исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 5.4 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә заявка бирүчеләргә карата таләпләрне һәм заявка бирүченең әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен аның тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм әлеге Тәртипнең 3.1, 3.2, 3.4, 3.5 пунктлары нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 4.2 – 4.6 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

заявка бирүчеләргә сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза кую вакытын;

субсидия бирү турында килешү төзүдән читләшкән сайлап алу җиңүчеләрен тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда, шулай ук вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруның сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган датасын;

әлеге критерийлардан чыгып сайлап алына торган, субсидия алу хокукына ия булган заявка бирүчеләрне сайлап алу критерийларын.»;

4.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Кәгазьдә тапшырылган заявкалар (шул исәптән кулланылмаганнары да) – вәкаләтле оешмада, ә электрон рәвештә тапшырылган заявкалар сервиста саклана.»;

5.1 пунктның өченче абзацында «, максатларын» сүзен төшереп калдырырга;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Заявка бирүчегә бирелә торган субсидия күләме ($S_{гомуми}$) вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_{гомуми} = S_1 + S_2,$$

монда:

$S_1$ – бер ставкалы тариф буенча кулланылган электр энергиясе расходларына түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия күләме, өстәлгән кыйммәткә салымнан башка сум, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_1 = \Sigma\, W_{факт\ i} \times (T_{факт\ i} - T_{вн\ i}),$$

монда:

$W_{факт\ i}$ – әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелә торган документ нигезендә заявка бирүчегә элегрәк субсидия бирелмәгән i аенда фактта кулланылган электр энергиясенең (югары көчәнеш диапазонлы (дәрәҗәле) электр энергиясеннән тыш) күләме, кВт × сәг;

$T_{факт\ i}$ – i аена Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020 – 2024 елларга Татарстан Республикасы территориясендә челтәрле оешмалар челтәрләре буенча электр энергиясен тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләргә бердәм (пар казаннары) тарифлар билгеләү турында» 2019 елның 19 декабрендәге 3-26/э номерлы карарының (алга таба – Карар) 1 нче кушымтасында билгеләнгән, заявка бирүче тарафыннан әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелә торган документлар нигезендә i аенда заявка бирүченең фактта файдаланылган көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча түләнә торган бердәм (пар казаннары) тарифлар (ы), сум/кВт × сәг (өтердән соң ике билгене исәпкә алып);

$T_{вн\ i}$ – Карар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә югары көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча челтәрле оешмалар челтәрләреннән билгеләнгән чорга башка кулланучылар тәэмин ителә торган электр энергиясен тапшыру буенча хезмәт күрсәтүләр өчен i аена Карарда билгеләнгән бердәм (пар казаннары) тарифлар(ы), сум/кВт ×сәг (өтердән соң ике билгене исәпкә алып);

$S_2$ – ике ставкалы тариф буенча кулланылган электр энергиясе расходларына түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия күләме, өстәлгән кыйммәткә салымнан башка сум, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_2 = \Sigma\, (M_{факт\ i} \times (T1_{факт\ i} - T1_{вн\ i}) + W_{факт\ i} \times (T2_{факт\ i} - T2_{вн\ i})),$$

монда:

$M_{факт\ i}$ – әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелә торган документ нигезендә заявка бирүчегә элегрәк субсидия бирелмәгән i аенда фактта кулланылган куәтнең (югары көчәнеш диапазонлы (дәрәҗәле) электр энергиясеннән тыш) күләме, кВт× ай;

$T1_{факт\ i}$ – электр челтәрләрен карап тоту өчен i аена Карарда билгеләнгән, әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелгән документлар нигезендә заявка бирүче тарафыннан аның фактта файдаланылган көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча түләнә торган ставка, сум/кВт × ай (өтердән соң ике билгене исәпкә алып);

$T1_{вн\ i}$ – югары көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча электр челтәрләрен карап тоту өчен i аена билгеләнгән, Карарда каралган ставка, сум/кВт × ай (өтердән соң ике билгене исәпкә алып);

$W_{факт\ i}$ – әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелә торган документ нигезендә заявка бирүчегә элегрәк субсидия бирелмәгән i аенда фактта кулланылган электр энергиясенең (югары көчәнеш диапазонлы (дәрәҗәле) электр энергиясеннән тыш) күләме, кВт × сәг;

$T2_{факт\ i}$ – электр челтәрләрендәге технологик расходка (югалтуга) түләү өчен i аена Карарда билгеләнгән, әлеге Тәртипнең 3.1 пунктындагы дүртенче абзацы нигезендә бирелгән документлар нигезендә заявка бирүче тарафыннан аның фактта файдаланылган көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча түләнә торган ставка, сум/кВт × сәг (өтердән соң ике билгене исәпкә алып);

$T2_{вн\ i}$ – югары көчәнеш диапазоны (дәрәҗәсе) буенча электр челтәрләрендәге технологик расходка (югалтуга) түләү өчен i аена билгеләнгән, Карарда каралган ставка, сум/ кВт × сәг (өтердән соң ике билгене исәпкә алып).

Субсидия күләме әлеге Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә тапшырыла торган документларга таянып исәпләп чыгарылган, фактта тотылган һәм документаль расланган чыгымнар күләменнән арта алмый.»;

5.5 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

5.6 пунктта:

дүртенче абзацта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында:

башисемендә «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«түбәндәге көчәнеш диапазонындагы (дәрәҗәсендәге) электр энергиясен кулланучы булып тора (кирәклесенең астына сызарга);»;

әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасында:

башисемендә «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасындагы башисемендә «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипнең 5 нче кушымтасындагы башисемендә «2021 елда» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Тәртипнең 2.1 пунктындагы өченче абзацының, Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы җитмешенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

2021 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 1 сентябрь, 940 нчы
карары редакциясендә)

Форма

Кулланылган электр энергиясе расходларына түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булып торган индустриаль (сәнәгать) парклар(ы)ның резидентларына һәм идарәче компанияләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алуга
гариза

| Т/с | Белешмәләрнең исеме | Заявка бирүченең мәгълүматлары |
|---|---|---|
| 1. | Заявка бирүченең тулы исеме | |
| 2. | Заявка бирүченең ИННы | |
| 3. | Индустриаль (сәнәгать) парк(ы)ның исеме | |
| 4. | Заявка бирүченең категориясе (идарәче компания / резидент) | |
| 5. | Юридик затның адресы / индивидуаль эшкуарның яшәү урыны | |
| 6. | Җитәкченең Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда) | |
| 7. | Сорала торган субсидиянең суммасы (цифрлар белән сумнарда күрсәтелә) | |
| 8. | Банк реквизитлары, шул исәптән банк исеме, ИНН, КПП, исәп-хисап счеты, БИК, корреспондент счеты | |
| 9. | Җитәкченең телефон номеры | |
| 10. | Җаваплы затларның элемтәгә керү өчен телефон номеры, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) | |
| 11. | E-mail | |
| 12. | Электр энергиясен тапшыру өчен заявка бирүче тарафыннан кулланыла торган тариф: бер ставкалы һәм (яки) ике ставкалы | |

Моның белән заявка бирүче «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә заявка бирүче турында, тапшырыла торган заявка турында мәгълүмат, заявка бирүче турында, сайлап алуга бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) үзенең ризалыгын белдерә, заявкада бирелгән мәгълүматның дөреслеген гарантияли һәм заявка бирүчедән дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарында һәм җирле үзидарә органнарында тапшырылган белешмәләрне раслый торган мәгълүматны рәсми соратып алу хокукын раслый.

Җитәкче ________________________ ________________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У. (булганда)

20___ ел, «____»__________

________________________________